| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЗЕЛЕНАЯ РОЩА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 31 июле** **№ 21**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»2015 елның 26 октябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 маддәсенә (икенче өлеш) 2000 елның 5 августындагы 117-ФЗ номерлы (04.06.2018 редакциясендә) таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»2015 елның 26 октябрендәге 10 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктның 3 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зеленая Роща авыл җирлеге буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы, Совет рәисе А.А.Потапов